КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 июль г.Казань № 578

Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $69^2$ статьясындагы 3 нче пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) (алга таба – региональ исемлек (классификатор)) кулланып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына дәүләт йөкләмәсеннән башлап гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына муниципаль йөкләмәләрдән башлап, региональ исемлекне (классификаторны) кулланып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәне формалаштыруны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау турында» 2015 ел, 16 июль, 518 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 8 апрель, 205 нче карарының 1 пункты.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 18 июль, 578 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) формалаштыру, алып бару һәм раслау
ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) (алга таба – региональ исемлек (классификатор)) формалаштыру, алып бару һәм раслау кагыйдәләрен билгели.

2. Региональ исемлек (классификатор) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Региональ исемлекне (классификаторны) формалаштыру һәм алып бару эшчәнлеген оештыру-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге) гамәлгә ашыра.

3. Региональ исемлек (классификатор) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (www.budget.gov.ru) Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## II. Региональ исемлеккә (классификаторга) кертелә торган мәгълүмат составы

4. Региональ исемлектә (классификаторда) һәр дәүләт хезмәтенә (муниципаль хезмәткә) яки эшкә карата түбәндәге мәгълүмат бирелә:

а) дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) яисә эш исеме;

б) Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча продукциянең гомумроссия классификаторының дәүләт хезмәтенә (муниципаль хезмәткә) яки эшкә туры килә торган кодларына күрсәтмә;

в) дәүләт хезмәтенең (муниципаль хезмәтнең) яки эшнең түләүсез булуына яки түләүле булуына күрсәтмә;

г) дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) яки эшнең эчтәлеге;

д) дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) күрсәтү яки эш башкару шартлары (формалары);

е) дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) күрсәтергә яки эш башкарырга хокуклы дәүләт (муниципаль) (бюджет, автоном, казна) учреждениесе тибы (типлары);

ж) чыгым йөкләмәләренә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокук актлары (муниципаль хокукый актлар) нигезендә дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) күрсәтү яки эш башкару кирә торган гавами-хокукый оешмага күрсәтмә;

з) дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) күрсәтүдән яки эш башкарудан файдаланучылар категорияләре;

и) дәүләт хезмәтенең (муниципаль хезмәтнең) яки эш башкаруның сыйфатын һәм күләмен тасвирлый торган күрсәткечләр исеме (булган очракта);

к) региональ исемлекне (классификаторны) формалаштыру һәм (яки) аңа үзгәрешләр кертү өчен нигез булып торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокук актлары (муниципаль хокук актлары) (алга таба – региональ исемлекне (классификаторны) формалаштыру һәм (яки) аңа үзгәрешләр кертү өчен нигез булып торган актлар) реквизитлары (статьяларын, өлешләрен, пунктларын, пунктчаларын, абзацларын күрсәтеп);

л) региональ исемлеккә (классификаторга) кертелгән дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) яки эш турында башка мәгълүмат, региональ исемлеккә кертелә торган үзгәрешләр, региональ исемлекнең (классификаторның) яңа редакциясе.

## III. Региональ исемлекне (классификаторны) формалаштыру һәм раслау

5. Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләрен (классификаторларын) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (www.budget.gov.ru) урнаштырганнан соң 30 эш көне эчендә региональ исемлек (классификатор) проектын бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча формалаштыра һәм килештерү өчен түбәндәгеләргә җибәрә:

дәүләт бюджет һәм (яки) автоном учреждениеләргә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, ведомство буйсынуында дәүләт казна учреждениеләре булган һәм әлеге учреждениеләргә карата алар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләрен формалаштыру турында карар кабул ителгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә (алга таба – гамәлгә куючылар);

дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтү өчен нигез булып торган нигезләмәләрнең булу-булмавын, мәгълүматны кертмәүне (тулысынча кертмәүне) бәяләү өчен Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары).

6. Гамәлгә куючылар, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, җирле үзидарә органнары 15 эш көне эчендә региональ исемлек (классификатор) проектын карап тикшерә һәм региональ исемлек (классификатор) проектына үзгәрешләр кертү, аңа яңа хезмәтләрне, эшләрне кертү турындагы тәкъдимнәр (булган очракта) белән килештерү нәтиҗәләрен бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә җибәрә.

7. Гамәлгә куючыларның, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, җирле үзидарә органнарының тәкъдимнәре булмаган очракта, Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге региональ исемлек (классификатор) проектын килештерү нәтиҗәләре кергән көннән 15 эш көне эчендә региональ исемлек (классификатор) проектын раслауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

8. Гамәлгә куючы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәренең бу Тәртип таләпләренә, Татарстан Республикасы норматив хокук актларына, муниципаль хокук актларына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең (муниципаль учреждениеләрнең) устав эшчәнлегенә туры килмәве ачыкланган очракта, Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге тәкъдимнәр кергән көннән 15 эш көне эчендә аларны гамәлгә куючыга, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, җирле үзидарә органнарына эшләп бетерү өчен кире кайтара яисә региональ исемлек (классификатор) проектына үзгәрешләр кертүне килештерүдән баш тарту турындагы мәгълүматны гамәлгә куючыга, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, җирле үзидарә органнарына баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп хәбәр итә.

9. Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенең региональ исемлек (классификатор) проектына үзгәрешләр кертү турында гамәлгә куючылар, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәренә карата күрсәтмәләре булмаган очракта, Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге әлеге тәкъдимнәр кергән көннән 30 эш көне эчендә региональ исемлек (классификатор) проектын эшләп бетерә һәм аны раслауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

## IV. Региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү

10. Региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү, бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүмат үзгәргән очракта, шул исәптән региональ исемлекне (классификаторны) формалаштыру һәм (яки) аңа үзгәрешләр кертү өчен нигез булып торган актларны кабул итүгә һәм (яки) үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлгә куючылар, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәр, бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күздә тотылган очракларда, гамәлгә куючы, җирле үзидарә органнары тарафыннан формалаштырыла һәм бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә җибәрелә.

12. Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге гамәлгә куючыларның, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, җирле үзидарә органнарының региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәре кергән көннән 15 эш көне эчендә:

региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерә;

тәкъдимнәрнең бу Тәртип таләпләренә, Татарстан Республикасы норматив хокук актларына, муниципаль хокук актларына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең (муниципаль учреждениеләрнең) устав эшчәнлегенә туры килмәве ачыкланган очракта, тәкъдимнәрне гамәлгә куючыга, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, җирле үзидарә органнарына эшләп бетерү өчен кире кайтара яисә региональ исемлек (классификатор) проектына үзгәрешләр кертүне килештерүдән баш тарту турындагы мәгълүматны гамәлгә куючыга, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, җирле үзидарә органнарына баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп хәбәр итә;

тәкъдимнәргә карата күрсәтмәләр булмаган очракта, региональ исемлеккә (классификаторга) үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеге (классификаторы)

| Т/с | Реестр саны | Хезмәт (эш) исеме | Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча продукциянең гомумроссия классификаторы коды | Түләүле (түләүсез) хезмәт (эш) | Хезмәт күрсәтүнең (эш башкаруның) эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү (эш башкару) шартлары (формалары) | Хезмәт күрсәтүче (эш башкаручы) учреждениесе тибы | Гавами-хокукый оешма төре | Хезмәт күрсәтүдән (эш башкарудан) файдаланучылар категориясе | Хезмәт (эш) күләме күрсәткечен һәм үлчәү берәмлеге | Хезмәт (эш) сыйфаты күрсәткече һәм үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү (эш башкару) өчен нигез булып торган норматив хокук актлары реквизитлары | Башка мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |

---